**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**ТЮЛЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Фатыха Хусни ул., д. 10, с. Тюлячи
422080
тел. (факс): (84360) 2-02-12
E-mail: Tlc.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Фатых Хөсни ур., 10 нче йорт,
Теләче авылы
422080
тел. (факс): (84360) 2-02-12
E-mail: Tlc.Tul@tatar.ru

ОКПО 48674966 ОГРН 1021607156691 ИНН/КПП 1619000368/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 1** **« 17 » февраля 2026г.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге генераль планы проекты буенча гаммәви тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә яшәүче гражданнарның генераль планнар проекты буенча фикер алышуда гаммәви тыңлаулар уздыру юлы белән катнашу хокукларын үтәү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2026 елның 25 февралендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы "Теләче авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гаммәви тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы "Теләче авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гаммәви тыңлауларны 2026 елның 25 февралендә түбәндәге адреслар буенча үткәрергә:

2.1. 10:00 сәгатьтә Теләче муниципаль районы Район мәдәният йорты бинасында, адресы: Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Теләче авылы, Белов урамы, 5 йорт.

2.2. 11:00 сәгатьтә Ачы авыл мәдәният йорты бинасында, адресы: Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Ачы авылы, Ленин урамы, 31 йорт.

2.3. 12:00 сәгатьтә, адресы: Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Комаровка авылы, Гагарин урамы, 1 йорт.

2.4. 13:00 сәгатьтә, адресы: Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Екатериновка авылы, Советская урамы, 15 йорт.

3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. 2026 елның 18 февраленә кадәр әлеге карарны, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты материалларын җирле үзидарә органының мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (tulachi.tatarstan.ru), Теләче авыл җирлеге бүлегендә-бүлекчә: җирлекне территориаль планлаштыру документациясе.

3.2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3.3. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләүчеләрне («ГК-Групп» ҖЧҖ) гаммәви тыңлауларда катнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2024 елның 01 ноябрендәге 145 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Теләче районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гаммәви тыңлауларны "Татарстан Республикасы Теләче районы Теләче авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гаммәви тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе нигезендә уздырырга.

5. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

6. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектына кертелгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем оештырырга һәм аның составын 2 номерлы карар нигезендә расларга.

7. Генераль план проекты буенча гаммәви тыңлаулар беркетмәсен һәм гаммәви тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы Бәяләмәне «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын раслау турында йә генераль план проектын кире кагу һәм аны эшләп бетерүгә җибәрү турында Карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советына җибәрергә., шулай ук генераль план проекты буенча гаммәви тыңлаулар беркетмәсен һәм гаммәви тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы Бәяләмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Теләче муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

8. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты экспозициясен үткәрү вакыты: 2026 елның 18 февраленнән 2026 елның 24 февраленә кадәр эш көннәрендә һәм вакытында, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты экспозициясен ачу урыны 422094, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Теләче авылы Фатыйх Хөсни ур., 10 йорт адресы буенча.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге башлыгы
А.Г. Фатхуллин

Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгының
17.02.2026 ел 1 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге генераль планы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе

1. "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча тәкъдимнәр Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Башкарма комитетына 422080, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Теләче авылы, Фатыйх Хөсни урамы, 10 йорт адресы буенча язма формада тапшырыла.

_ Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы рәсми сайтында (tulachi.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат стендларына, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ruInsert урнаштырылган көннән алып 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр эш көннәрендә 2026 елның 18 февраленнән 2026 елның 24 февраленә кадәр кабул ителә.

2. Гаммәви тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризаләр: 422080, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Теләче авылы, Фатыйх Хөсни урамы, 10 йортка шәхси рәвештә яки почта аша (конвертта “Теләче авыл җирлеге генераль планы буенча фикер алышу” дип күрсәтеп) тапшырыла.

Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге
башлыгының 17.02.2026 ел 1 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектына кертелгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем составы

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Маракова Р.Р. – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;

Хаҗиев Рәвис Масгут улы - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча);

Нуртдинов Рәис Рөстәм улы - Татарстан Республикасы Түләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча);

Ханафиева Эльвира Әдхәм кызы - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге башкарма комитеты өлкән белгече.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең генераль планы проектын эшләүчеләр - ҖЧҖ «ГК-Групп» (килешү буенча).